| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2025 № 276

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында " 15.01.2020 ел, № 12 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының " Автобуслар классы киселешендә 1 километр йөрүнең иң чик үзкыйммәте турында «27.12.2024 ел, № 1221 карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында " 15.01.2020 ел, № 12 карарына түбәндәгеләрне кертергә:

үзгәреш: 1.1.1 нче кушымтаның 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә «5.1. Муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы ташучының төшеп калучы керемнәрен каплауга субсидия күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча исәп-хисап юлы белән билгеләнә::

С = з-д

Кая :

С - субсидияләр күләме, мең сум;

З - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 27.12.2024 елгы 1221 номерлы карары белән расланган транспорт чарасының классына (1 километрга 47 сум 50 тиен) һәм маршрут озынлыгына бәйле рәвештә 1 км йөрешнең иң чик норматив

үзкыйммәтен исәпкә алып, даими рәвештә муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуга чыгымнар;

Д - даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча йөргән өчен түләүдән алынган керемнәр мең сумнарда.

Ташучының керемнәре составында керемнәрнең түбәндәге төрләре исәпкә алына:

муниципаль ташулар вакытында пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга бер тапкыр бирелә торган билетлар сатудан кергән табыш;

ташучының гражданнарның ташламалы категорияләрен социаль йөртү билетлары буенча йөртүгә бәйле барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан бирелә торган чыгымнарын компенсацияләү суммалары.

Шул ук вакытта ташучының керемнәре транспорт чарасының 50% тан да ким булмаган тулылыгы күрсәткеченнән чыгып исәпләнә.»

1.2. 2 нче кушымтаны кушымтада бирелгән яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

2.Әлеге карарның гамәлдә булуын 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http:// бастырып чыгарырга: pravo.tatarstan.ru.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.И. Ислямовка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы: С.Ю.Зайцев

ТР Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.01.2020 № 12
карарынына кушымта

(ТР Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының
13.10.2025 № 276
карары редакциясендә 2 нчекушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия составы

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Ислямов И.И. | Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |

Комиссия членнары:

| | |
|---|---|
| Муратшин И.И. | Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары |
| Левашова Л.А. | Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| Сарвартдинова Р.Р. | Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| Оверина Е.Г. | Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |